ГЛАВА ЯМБУЛАТОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Центральная, д.5, с. Ямбулатово,
422587

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ЯМБУЛАТ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Узәк ур., 5 нче йорт, Ямбулат авылы,
422587

Тел.: (84379) 36-5-18 факс: (84379) 36-5-18

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

19 сентября 2017 г. с.Ямбулатово № 8

Җирле референдум уздыру инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22 ст., 56 ст. 1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 20 статьясындагы 1 п. 1 пункты, Ямбулат авыл җирлеге Уставының 11 ст.

КАРАР БИРӘМ:

1. Ямбулат авыл җирлеге территориясендә җирле референдум уздыруның түбәндәге мәсьәләләре буенча уртак инициативасын чыгарырга:

«2018 елда авыл җирлегенең җирле референдумда катнашу хокукына ия булган һәр кешесеннән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне үтәү буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә алынган акчалар юлламасы белән килешерсезме:

- Ямбулат авылы җирлегендә урнашкан Ямбулат, Казыльяры, Крестниково авылларындагы чишмәләрнең санитар зонасын төзекләндерү һәм норматив хәлгә китерү:

ӘЙЕ ЮК

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карар аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

ТР Югары Ослан муниципаль районы
Ямбулат авыл җирлеге башлыгы : М.Н. Әхмәтҗанов